**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе** шәһәренең **муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе Таҗи Гыйззәт исемендәге 3нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

# Тема: "Сыйфат" темасын кабатлау

**6нчы сыйныф (татар төркеме)**

**Сингапур укыту методын кулланып уздырылган дәрес эшкәртмәсе**

**Укытучы: Ишмөхәммәтова В.М.**

**20 декабрь 2013**

**Дәреснең темасы:** “Сыйфатлар” темасын кабатлау.

**Дәреснең максатлары:**

**1. Белем бирү максаты** - Укучыларның “Сыйфат” темасы буенча алдагы дәресләрдә өйрәнгән белемнәрен: мәгънәсен, сорауларын, кушымчаларын, дәрәҗәләрен искә төшерү, башка сүз төркемнәреннән аеру, сөйләмдә дөрес куллана белү күнекмәләре булдыру.

**2. Фикер сәләтен үстерү максаты -** Укучыларның логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып-белүне үстерүгә ярдәм итү.

**3. Тәрбияви максат** - Аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру.

**Җиһазлау:** компьютер, карточкалар, төсле кәгазь битләре, структураларның алгоритмы, МЭНЭДЖ МЭТ, таймер, татар теле дәреслеге.

**Дәреслек:** Максимов Н.В., Хәмидуллина М.З. Татар теле. 6нчы сыйныф: - Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010

**Дәрес тибы:** белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.

**Кулланылган структуралар:**

МЭНЭДЖ МЭТ

СИНГЛ РАУНД РОБИН

ФРЕЙЕР МОДЕЛЕ

СИМАЛТИНИУС РАУНД ТЭЙБЛ

МИКС-ФРИЗ-ГРУП

КОНЭРС

ДЖОТ ТОТС

ТИК-ТЭК-ТОУ

ФИНК-РАЙТ-РАУНД РОБИН

## Дәрес барышы

**1. Оештыру.**

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру. Хәерле көн теләү. Кунаклар белән исәнләшү.

Дежур укучыны тыңлау. (Өй эше – “Сыйфатлар” темасын кабатларга)

Дәреснең максаты белән таныштыру.

- Укучылар, бүген без сезнең белән дәрестә сыйфат сүз төркемен кабатларбыз, ныгытырбыз, белемнәрне системага салырбыз.

**2. Актуальләштерү.**

Проблемалы сорау кую.

- Балалар, ә сез ничек уйлыйсыз, без бу теманы ни өчен өйрәнәбез? Сыйфатлар безгә кайда, нигә кирәк булачаклар? Әйдәгез әле, шул турыда төркемнәрдә бергәләп уйлашыйк. СИНГЛ РАУНД РОБИН структуасы. Сезгә 2 минут вакыт бирелә, аннары һәр өстәләдән берәр фикерне тыңларбыз. (Укучыларның җаваплары тыңлана).

- Нинди нәтиҗәгә килдек? (-Сыйфатларны өйрәнергә кирәк!)

-Менә сез аларны нинди дәрәҗәдә өйрәндегез микән, әйдәгез әле, тикшереп карыйк. Без аны ФРЕЙЕР МОДЕЛЕН кулланып тикшерербез.

Укучылар, сезнең алда альбом битләре ята, башта аны икегә, аннан тагын икегә бүләбез. Шул бүленгән кисәкнең бер почмагын әз генә бөклибез һәм альбом битен вертикаль рәвештә ачып каршыбызга куябыз. Әлеге биттәге бөкләнгән урыннарны карандашлар белән кабатлап чыгабыз һәм уртага *сыфат* дип язабыз. Беренче баганага сыйфатның билгеләмәсен, икенче баганага характеристикасын, өченче баганага мисаллар, дүртенче баганага капма-каршы мисалларны язабыз. Һәр кәгазь битен мөстәкыйль рәвештә тутырабыз. Сезгә барлыгы 5 минут вакыт бирелә.

**Билгеләмә**

Сыйфат – предметның билгесен белдерә, нинди? кайсы? Кайдагы? срауларына җавап бирә.

**Характеристика**

Асыл һәм нисби була

Дәрәҗәләре бар

Сыйфатланмыш

Җөмләдә аергыч, хәбәр, хәл була

**ИСЕМ**

**Мисаллар**

сары

зур

кечкенә

матур

кызыл

**Капма-каршы мисаллар**

бара

сөйли

ике

өстәл

урындык

- Вакыт чыкты. 3нче номерлы укучы эшләрне миңа җыеп бирә. Мин аларны билге куйганда исәпкә алачакмын.

**3. Кабатлау, ныгыту.**

- Яхшы! Хәзер телдән кабатлауга күчәбез. Сыйфатка нинди билгеләмә бирдегез?

- Сыйфатны нинди 2 зур төркемгә бүлдек?

- Асыл һәм нисби сыйфатларны ничек итеп аерабыз?

- Тикшереп карыйбыз: барыбыз да аера беләбезме икән? Парларда эшләр өчен карточкалар өләшәм. Анда язылган җөмләләрдән А варианты асыл сыйфатларны күчерә, Б варианты – нисби сыйфатларны. СИМАЛТИНИУС РАУНД ТЭЙБЛ структурасы буенча эшләнә торган бу эшкә 4 минут вакыт бирелә. Дәфтәрләргә матур итеп числоны язабыз һәм эшли башлыйбыз.

- Вакыт бетте. Эшләрне тәмамлыйбыз. Хәзер дәфтәрләрне алышып тикшерәбез. Ничәсе дөрес – билге шундый. Тактада язылган сүзләр:

| **Асыл** | **Нисби** |
|---|---|
| Зур | Җәйге |
| Матур | Фәнни |
| Зәп-зәңгәр | Тарихи |
| Куе | Кичке |
| Кечкенә | Кышкы |

**Физкультминут**

- Ә хәзер укучылар бераз ял итеп алабыз. *МИКС – ФРИЗ – ГРУП* структурасын кулланырбыз. Укучылар, без хәзер барыбыз да бер әйләнә ясап басабыз. Музыка кушыла, сез шул музыкага бии-бии әйләнәсез. Музыка туктагач, сез бер урында басып каласыз. Шуннан соң мин сезгә сорау бирәм, сез шул сорауның җавабын миңа укучылар саны ярдәмендә күрсәтергә тиеш буласыз.

1. *Исем* сүзендә ничә хәреф бар? (4)
2. Татар телендә ничә килеш бар? (6)
3. *Сыйфат* сүзендә ничә тартык аваз бар? (4)
4. Сыйфатларны ничә төркемгә бүлдек? (2)
5. Сыйфатларның ничә дәрәҗәсе бар? (4)

- Нинди дәрәҗәләр? Сүзләрнең нинди дәрәҗәдә икәнен аера белүегезне КОНЭРС структурасын кулланып тикшерербез. Мин сезгә төрле дәрәҗәдәге сүзләр

язылган карточкалар өләшәм. Сүзләрегез нинди дәрәҗәдә, шул почмакка басасыз. Бер-берегезгә сүзләрнке укыйсыз, тикшерәсез һәм шул дәрәҗә турында сөйләргә өйрәнәсез. 2 минут вакытыгыз бар.

- Тикшерәбез. Гади дәрәҗә. Сүзләрне укыйбыз, бер җөмлә төзибез.

Чагыштыру дәрәҗәсе. Нинди билге буенча таптыгыз? Язганда нинди кагыйдә бар?

Артыклык дәрәҗәсе. Нинди сүзләр ярдәмендә ясыйбыз? Кып-кызыл ясалышы буенча нинди сүз?

Кимлек дәрәҗәсенең нинди үзенчәлеге бар?

- Рәхмәт, утырдык. Ә хәзер үзегез белгән матур сыйфатларны кәгазь битләренә язып, дусларыгыз белән уртаклашыгыз. Бу безнең ДЖОТ ТОТС структурасы. Битләрне 2нче номерлы укучылар өләшә. Берәр сүз язасыз, укыйсыз, уртага куясыз. Аннары 1нче номер сүзләрне сайлап ТИК-ТЭК-ТОУ структурасы буенча эшләргә әзерли. Сезгә 3 минут вакыт бирелә.

- ТИК-ТЭК-ТОУ структурасы буенча сүзләрдән җөмләләр төзергә кирәклеген беләсез. Сүзләрне я диогональ, я вертикаль, я горизонталь буенча алырга кирәклеген онытмыйбыз. Берәр җөмләне дәфтәргә язабыз. Аннары бер-беребезгә укыйбыз. Тикшерәбез. Өстәлдән укырга берәр җөмлә сайлыйбыз. (ФИНК-РАЙТ-РАУНД РОБИН структурасын кулланабыз.)

3нче номерлы укучы өстәлдә тәртип урнаштыра.

Җөмләләр төзүне өйдә дәвам итәрбез.

- Менә без сезнең белән “Сыйфат” темасын кабатлап чыктык. Хәзер әйтегез әле: бу теманы кем “5”легә үзләштердем, дип уйлый. Кем белемен “4”лелек ди? Ни өчен? Ә кем үзенә “3”ле куя? Ни өчен? Бу теманы ныгытырга безнең әле тагын ике дәрес бар. Тырышлык булса, уңышлар да булыр!

Сау булыгыз, укучылар!